Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXVIII-2**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 25 мае

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Масловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 маддәсенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенә ярашлы рәвештә, муниципаль берәмлекнең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау, муниципаль берәмлек территориясен планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, шул исәптән җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның иң нәтиҗәле төрләрен сайлау мөмкинлеге бирү юлы белән, шулай ук 2023 елның 27 февралендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Масловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымта итеп бирелә торган Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен расларга.

2. Көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2021 елның 13 ноябрендәге XXIV-9 номерлы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Масловка авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карарын;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2020 елның 15 гыйнварындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карарын;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2019 елның 6 маендагы IV номерлы «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге 29 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» карарын;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2016 елның 26 декабрендәге 29 номерлы "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Масловка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре турында"гы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Масловка авылы, Үзәк урам, 13 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов